# Фитр сәдакасы

# زكاة الفطر

ALSARHAAN.COM

زكاة الفطر

**Фитр сәдакасы.**

اللغة التتارية

كيف  تطهر صيامك من النقص والكدر ؟ !

**Ничек итеп тоткан уразаны хата-кимчелекләрдән чистартып була?**

كيف تدخل السرور إلى قلوب الفقراء والمساكين ليفرحوا بالعيد كما تفرح ؟!

**Ничек итеп шушы ураза гаетендә мескен фәкыйрьләрнең күңелләренә шатлык хисе кертеп була?**

تأمل هذا الأثر.

عن ابن عباس رضي الله عنهما

**Ибн Гәббәстән, Аллаһ аларның икесеннән дә разый булсын, хәбәр ителәә:**

قال: فرض رسول الله صلى الله عليه وسلم زكاة الفطر. طهرة للصائم من اللغو والرفث وطُعمة للمساكين.

"Пәйгамбәребез ﷺ фитр сәдакасын фарыз итеп билгеләде һәм бу сәдака – ураза тотучының төрле начар буш сүзләрдән чистарынуы, һәм шулай ук мескеннәр өчен ризык булып тора".

وزكاة الفطر واجبة على كل مسلم عن نفسه وعن من تلزمه نفقته كزوجته وأولاده. فلا يشترط أن يمتلك نصابا معينا من المال.

Әгәр мөселман кешесендә бер көнгә җитәрлек ризыктан артык ризык бар икән, аңа үзе өчен һәм ул тәэмин итергә тиешле булган кешеләре өчен фитр сәдакасын бирү уәҗиб булып тора. Хәтта аның малы нисаб күләменә җитмәсә дә.

والقدر الواجب عن كل شخص صاع من كل حب وثمر يقتات الناس عليه. كالتمر والأُرز والعدس.

**Фитр сәдакасы һәрбер кешедән бер саг күләмендә кеше ризыкка куллана торган дөге, борчак шикелле ярма бөртегеннән, я инде финик шикелле җимештән бирелә.**

عن ابن عمر رضي الله عنهما قال
فرض رسول الله صلى الله عليه وسلم: زكاة الفطر صاعا من تمر او من شعير على العبد والحر والذكر والأنثى والصغير والكبير من المسلمين.
وأمر بها أن تؤدى قبل خروج الناس إلى الصلاة.
وتجب بغروب آخر يوم من رمضان.

**Ибн Гәббәстән, Аллаһ аларның икесеннән дә разый булсын, хәбәр ителә:**

"Аллаһның илчесе ﷺ һәрбер мөселманга фитр сәдакасын фарыз итеп билгеләп, аны бер саг күләмендә финик җимешеннән, я инде арпа кебек бөртектән бирергә әйтте; кол булганына да, кол булмаганына да, хатын-кызга да, ир кешегә дә, кечесенә дә, зурысына да. Һәм бу сәдака рамазан аеның ахыргы көнендә кояш батканнан башлап кешеләр гает намазына чыкканчы бирелә".

والأفضل أن يخرجها قبل صلاة العيد.

Ләкин иң яхшысы бу сәдаканы гает намазы алдыннан бирү.

ولا بأس أن يخرجها العيد بيوم أو يومين. أي من ليلة ثمان وعشرين. لأن الشهر يكون تسعا وعشرين ويكون ثلاثين.

Һәм шулай ук гает көненнән бер-ике көн алдан бирелсә дә зыян булмас. Ягъни рамазан аеның егерме сигезенче төненнән соң. Чөнки рамазан ае егерме тугыз, я инде утыз көннән килә.

ولا يجوز تأخيرها بعد صلاة العيد. ومن لم يخرجها يوم العيد فهوآثم. إلا أن يكون معذورا. ويجب قضاؤها. فبادر بها.

Сәбәпсез фитр сәдакасын гает намазыннан соң бирермен дип калдырырга ярамый. Мондый кешегә гөнаһ язылa һәм аңа бу сәдаканы соңга калып булса да бирергә кирәк. Һәм бу гамәлдә ашыгырга кирәк.

Аллаһ Раббыбыз әйтте:
«Әй иман китергән бәндәләр! Үзегезне ут газабыннан сатып алу сәүдәсе булмас, дуслык һәм шәфәгать итү эшләре булмас көн килеп җиткәнче, Мин сезгә биргән байлыктан Аллаһ юлында сарыф итегез. Кәфер булган кешеләр залимнәрдер».